ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 4 өлешендә «агып төшүче сулардагы һәм (яисә) дренаж суларындагы» сүзләрен «агып төшүче сулардагы, шул исәптән дренаж суларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 42 статьяда:

а) исемдә «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экология экспертизасы уздыруны, шул исәптән аны кабат уздыруны финанс белән тәэмин итү, заказчы дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле документларны, федераль законнар нигезендә экология экспертизасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендәге вәкаләтле башкарма органы дәүләт экология экспертизасын уздыруга билгели торган чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемны кертү шарты белән, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 – 4 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 43 статьяда:

а) исемдә «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

б) «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;